**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында 2016 елда Онкология авыруларына каршы көрәшү елын уздыру турында**

Халыкның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту мәсьәләләренә җәмгыятьнең игътибарын җәлеп итү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасында 2016 елда Онкология авыруларына каршы көрәшү елын уздырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:
бер ай эчендә Татарстан Республикасында 2016 елда Онкология авыруларына каршы көрәшү елын уздыру буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга;
бер ай эчендә Татарстан Республикасында 2016 елда Онкология авыруларына каршы көрәшү елын уздыру буенча төп чаралар планын эшләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына муниципаль берәмлекләр территорияләрендә Онкология авыруларына каршы көрәшү елын уздыру буенча эшне оештырырга тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына, җәмәгать берләшмәләренә һәм оешмаларына Татарстан Республикасында 2016 елда Онкология авыруларына каршы көрәшү елын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасында 2016 елда Онкология авыруларына каршы көрәшү елын уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2016 ел, 12 апрель
№ ПУ-339